**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛЬБАГУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОН

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш, Азнакаевский муниципальный район 423330

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Нефтяниклар ур., 30 нче йорт, Мәлбагыш авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

**Тел./факс(885592)3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь2 017 ел № 14

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 N 23-ТРЗ "Җирле референдум турында", «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясында карар бирәм:

1. Мәсьәлә буенча җирле референдум уздыру инициативасы белән чыгарга:

"Сез 2018 елда Мәлбагыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы ?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр куюны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны кертеп)

3) җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:

Мәлбагыш авылында Нефтьчеләр ур., 30 йорт (Башкарма комитетның административ бинасы); Мәлбагыш авылында Җәлил ур., 2 йорт (авыл мәдәният йорты); Түбән Якәй авылында , Кашапов ур., 23 йорт (ФАП); Каменка авылында Җәлил ур., 1 йорт

- Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru,

- «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык И.А.Әхтәмова